## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Бу сүзлек Татарстан Верховный Советы Президиумы каршындагы Дәүләт терминология комиссиясе кабул иткән „Татар әдәби теле терминологиясе өстендә эшләү өчен практик күрсәтмәләр-инструкция"гә (Казан, 1958 ел) нигезләнеп төзелде.

Сүзлек укытучылар, класс җитәкчеләре, тәрбиячеләр һәм педагогия институтлары һәм училищеларында укучылар өчен кулланма булыр дип күздә тотыла. Мәгариф работниклары, тәрҗемәчеләр, табигый-фәнни, атеистик һәм педагогик пропаганда алып баручыларга да аның файдасы булыр дип уйларга кирәк.

Сүзлеккә педагогика һәм психология фәннәренең төрле тармакларында очрый торган терминнар кертелде. Педагогика һәм психологиянең махсус тармаклары (логопедия, суггестопедия, сурдопедагогика, тифлопедагогика, олигофренопедагогика, психофизиология, патопсихология, социаль психология һ. б.) өлкәсендә аерым татарча сүзлекләр юк. Шуңа күрә бу фәннәрнең дә ешрак очрый торган төшенчәләрен алу һәм аңлату тиеш табылды. Фәнни-техник революция нәтиҗәсе буларак, фәннәр арасында бәйләнеш һәм белемнәр интеграциясе артты, педагогика һәм психологиягә кибернетика, бионика, генетика, медицина, психиатрия, педиатрия төшенчәләре дә шактый керде. Сүзлектә мондый чиктәш фәннәрдән кергән терминнарның тик педагогик һәм психологик аспекты гына бирелде.

Үзенең характеры белән сүзлек рус телендәге терминнарның татар телендәге тиңдәшен бирү белән генә чикләнергә тиеш иде. Ләкин татар телендә хәзерге көндә аңлатмалы-энциклопедик сүзлекләр булмау сәбәпле, авторлар кайбер авыр аңлаешлы һәм яңарак терминнарга кыскача аңлатмалар да бирергә кирәк таптылар. Бу аңлатмалар җәя эчендә күрсәтелде.

Рус телендәге күп мәгънәле терминның һәр мәгънәсенә татар телендә сүзләр табылганда, ул мәгънәләр нокталы цифрлар белән аерып бирелде. Мәсәлән:

**непосредственность** 1. риясызлык, саф күңеллелек; 2. арадашсыз, турыдан-туры эш итү

**чувствительный** 1. (тоюга) сизгер, сизгер тоючан; 2. хисчән искә бирелүчән, тиз әсәрләнүчән)

Күп мәгънәле сүз бер генә сүз белән тәрҗемә ителгәндә, аның мәгънәләре җәя эчендә цифрлар белән аерып күрсәтелде,

**бакалавр** бакалавр (1. элек Көнбатыш Европа университетларында, хәзер Англиядә беренче гыйльми дәрәҗә; 2. хәзерге Франциядә һәм кайбер илләрдә урта мәктәпне тәмамлап чыккан кеше)

**куратор** куратор (1. элек: уку округы попечителе; 2. элек: югары властьлар алдында Мәскәү университеты интересларын һәм эшләрен юллаучы; 3. Франциядә укучылар түгәрәге белән житәкчелек иткән укытучы; 4. үзенә беркетелгән аспирантларның фәнни хәзерлеге белән җитәкчелек итүче профессор; 5. югары уку йортларында студентлар группасы җитәкчесе)

Рус телендәге һәр терминга татарча адекват сүз-термин табарга тырышылды, аерым сүз булмаганда сүзтезмә белән тәрҗемә ителде; бер генә сүз яки сүзтезмә ачыклап бетермәсә, телдә йөргән синонимнары да күрсәтелде. Синонимнар киләчәктә берсен терминлаштыру яисә контекст таләбе буенча уңайлысын сайлап алу мөмкинлеген тудыра.

Тәрҗемә итеп булмаган очракларда рус сүзләре татар теленең грамматик формаларында алынды, мәсәлән: **грамотность** — грамоталылык, **дисциплинированность** — дисциплиналылык, **тактичность** — тактлылык һ. б.

Педагогика һәм психологиянең күп кенә күренешләре һәм процесслары югары нерв эшчәнлеге закончалыкларына, анатомия һәм физиология төшенчәләренә, философия һәм социология фәннәренә нигезләнә. Шуңа күрә педагогика һәм психология өлкәсендә бу фәннәр белән уртак атамалар да күп. Мондый терминнар педагогика һәм психология өлкәсендә кулланыла торган мәгънәләрендә бирелде.

Илебездәге мәгариф үсеше тарихыннан башлангыч мәгълүмат бирүне күздә тотып, кайбер уку-укыту учреждениеләре атамаларының да татарчага тәрҗемәләре (бик кыска гына аңлатмалар белән) китерелде.

Сүзлектә терминнар оялап бирелде: „*хис*" („**чувство**") сүзенә барлык хисләр, „*хәтер*" („**память**") сүзенә хәтер категорияләре, „*дәрес*" („**урок**") сүзенә дәреснең барлык типлары, „*ярсыткыч*" („**раздражитель**") сүзенә барлык эчке һәм тышкы ярсыткычлар, „*мәктәп*" („**школа**") сүзенә тарихи үсештә булган барлык тип мәктәпләр һ. б. керде.

Бу сүзлекне төзегәндә проф. В. М. Горохов, А. П. Касимов һәм В. Н. Хангильдин тарафыннан 1950 елда чыгарылган „Русча-татарча психология һәм педагогика терминнары сүзлеге" дә файдаланылды. Әйтелгән авторларның сүзлеге, кечкенә генә

күләмле булса да, үз заманында татар телендә педагогик һәм психологик әдәбият булдыруда уңай роль уйнады. Ләкин соңгы утыз-кырык ел эчендә педагогика һәм психология фәннәре бик алга китте, аларның яңа тармаклары һәм өлкәләре киң үсеш алды, фәнни терминнар саны артты. Шуңа күрә „Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге"н яңадан нәшер итү зарурлыгы туды.

Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеген эшкәртүдә фәнни рецензияләүнең әһәмияте зур булды. Шуңа күрә авторлар СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре филология фәннәре докторы Г. Х. Ахунҗановка, Казан дәүләт университеты профессоры филология фәннәре докторы Г. Ф. Саттаровка, Алабуга педагогия институты педагогика һәм психология кафедралары мөдирләре доцент Д. С. Ягфаровага һәм доцент Х. Х. Хәкимовка, РСФСР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалы өлкән гыйльми хезмәткәре педагогия фәннәре кандидаты Ф. Ф. Исламовка, Казан дәүләт педагогия институты доценты М. Р. Әхмәтҗановка һәм Арча педагогия училищесының педагогика һәм психология укытучысы Ш. М. Гайнетдиновка үзләренең рәхмәтләрен белдерәләр.

Сүзлек белән танышкан барлык укучылардан күзгә чалынган кимчелекләр, кирәкле үзгәрешләр һәм өстәмәләр турында үз фикерләрен Татарстан китап нәшрияты адресы буенча язып җибәрүләрен үтенәбез.

* * *

## Шартлы кыскартмалар

*иск.* — искергән
*к.* — кара
*мәс.* — мәсәлән
*тар.* — тарихи
*чаг.* — чагыштыр